ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

29.10.2025 № 793

**2026 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2007 елның 11 декабрендәге 448 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елга кушымтада китерелгәннәрне расларга:
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнарны;

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына мәгариф оешмаларын финанслауны әлеге карарның 1 нче пунктында расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

4. Карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты
җитәкчесенең 29.10.2025
793 нче номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 137122 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 209941 |